# Нәбирә Гыйматдинова бездә кунакта

**Ульяновск шәһәренең 17 нче санлы милли китапханәсендә татар язучылары һәм шагыйрьләре белән очрашу кичәләре ай саен диярлек үткәрелә. Шушы көннәрдә генә әлеге мәдәният учагына мәркәзебез Казаннан мәртәбәле кунак - танылган язучы, ТРның М.Җәлил, Г.Тукай исемендәге әдәби премияләре лауреаты Нәбирә Гыйматдинова килгән иде.**

Милләттәшләребез арасында «Ак торна каргышы», «Сихерче», «Фәрештәләр», «Бүре каны» әсәрләрен укымаган кеше сирәктер. Яхшылык һәм өмет белән сугарылган бу повестьларның исемнәрен әйтүгә, мөлаем гына елмаеп Нәбирә ханым күз алдына килеп баса. Семберлеләргә аны күзаллау гына түгел, язучыны үзен күреп, якыннан аралашу бәхете дә елмайды.

Очрашу башланыр алдыннан китапханә фойесында әдәбият сөючеләргә язучының яңа гына басылып чыккан китаплары тәкъдим ителде.

Нәбирә ханым иң әүвәл кыскача гына үзенең тормыш юлы белән таныштырып үтте. Ул Татарстанның Аксубай районы Карасу авылында туып үскән. Мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетында белем алган. Ә иң беренче әсәрләре матбугат битләрендә җитмешенче елларда күренә башлый.

- Әсәрләремнең геройлары барысы да тормыштан алынды. Аларның күбесе белән мин якыннан таныш.



Төп темаларымның берсе - хатын-кыз язмышы.

Кайбер каләмдәшләрем мине, сихерчеләр, им-том турында күп язасың, дип тәнкыйтьлиләр. Ни генә дисәләр дә, «Фәрештәләр», «Сихерче» дигән повестьларым да тормыштан алынды, аларда бернинди уйдырма да юк. Ә иң яратып язган иҗат җимешләремнең берсе - Татарстанның беренче президентының этисе Шәрип агага багышланган «Сагыну» романы. Минтимер Шәймиев бу әсәрне бик тә җылы кабул итте, хәтта рәхмәт йөзеннән гаиләбезгә зур фатир да бүләк итеп тапшырды,- диде язучы.

Нәбирә ханым очрашуда катнашучыларның күпсанлы сорауларына җаваплар да бирде.

Олпат язучыны сәламләргә өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рамис Сафин да килгән иде.

- Нәбирә ханымның китапларын һәрвакытта да бик яратып, кызыксынып укыйбыз. Ул кеше язмышларын оста тасвирлый, тирән анализ ясый,- диде мохтарият җитәкчесе һәм кунакка истәлекле бүләк тә тапшырды, ә кичәне матур итеп оештырган өчен китапханә хезмәткәре Гөлфия Сәмигуллинага рәхмәт сүзләрен юллады.

Өлкә автономиясенең язучылар белән эшләү бүлеге җитәкчесе Шәфикъ Иматдинов, «Өмет» газетасы редакциясе хезмәткәре Рузия Хәлимова, «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы рәисе Кәримә Алиуллина, өлкә татар язучылары берләшмәсе әгъзасы Нажия Шагаева, китапханә мөдире Ольга Юрлова ерак юлны якын итеп килгән каләм иясенә киләчәктә дә иҗат уңышлары юлдаш булуын теләделәр.

Китапханәнең татар бүлеге җитәкчесе Гөлфия Сәмигуллина истәлекле очрашуны оештыру максатында спонсорлык ярдәме күрсәткән танылган малтабар Илмас Ситдиковка олы рәхмәт сүзләрен ирештерде.

Рузия ХӘЛИМОВА.